# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О внесении изменений в Земельный кодекс Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
19 декабря 2018 года

**Статья 1**

Внести в Земельный кодекс Республики Татарстан (в редакции Закона Республики Татарстан от 18 января 2005 года № 4-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1998, № 8 (II часть); 1999, № 8 (I часть); 2005, № 1 (I часть), № 12 (I часть); 2006, № 7 (I часть); 2007, № 1 (I часть), № 4; 2008, № 5 (I часть); 2009, № 7 – 8 (III часть); 2010, № 11; 2011, № 11 (I часть); 2012, № 3, № 5 (I часть); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть), № 10 (I часть); 2016, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 40 (часть I); 2017, № 41 (часть I), № 52 (часть I), № 76 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 22 (часть I), № 78 (часть I) следующие изменения:

1) пункт $6^1$ статьи 3 изложить в следующей редакции:

«$6^1$) в пределах своей компетенции принятие решений об установлении публичных сервитутов; утверждение порядка установления и прекращения публичных сервитутов в интересах Республики Татарстан, за исключением случаев, предусмотренных главой $V^7$ Земельного кодекса Российской Федерации; утверждение порядка определения и выплаты соразмерной платы за публичный сервитут, за исключением случаев, предусмотренных Земельным кодексом Российской Федерации или федеральным законом; установление порядка определения платы по соглашению об установлении сервитута в отношении земельных участков, находящихся в собственности Республики Татарстан, и земельных участков, государственная собственность на которые не разграничена;»;

2) в статье 11:

а) в пункте 3:

в абзаце первом слова «охранные, санитарно-защитные и иные» исключить;

абзац второй признать утратившим силу;

б) пункт 4 признать утратившим силу;

3) в статье 12:

а) в пункте 6 третье и четвертое предложения исключить;

б) подпункт 2 пункта 7 после слова «коммуникаций» дополнить словами «в границах особо охраняемых природных территорий в случаях, установленных федеральным законом (в случае зонирования особо охраняемой природной территории – в границах ее функциональных зон, режим которых, установленный в соответствии с федеральным законом, запрещает размещение соответствующих объектов)»;

4) статью 13 изложить в следующей редакции:

«Статья 13. **Земли лесного фонда**

1. К землям лесного фонда относятся лесные земли и нелесные земли, состав которых устанавливается лесным законодательством.

2. Порядок использования и охраны земель лесного фонда устанавливается Земельным кодексом Российской Федерации и лесным законодательством.»;

5) в статье $28^1$:

а) наименование дополнить словами «(газопроводов, нефтепроводов и нефтепродуктопроводов, аммиакопроводов)»;

б) пункт 1 после слов «зоны трубопроводов» дополнить словами «(газопроводов, нефтепроводов и нефтепродуктопроводов, аммиакопроводов)»;

в) пункт 2 после слов «зоны трубопроводов» дополнить словами «(газопроводов, нефтепроводов и нефтепродуктопроводов, аммиакопроводов)»;

г) пункт 3 признать утратившим силу;

д) пункт 4 изложить в следующей редакции:

«4. Собственники земельных участков и лица, не являющиеся собственниками земельных участков, обязаны не препятствовать организации – собственнику объекта системы газоснабжения, нефтепровода или нефтепродуктопровода либо уполномоченной ею организации в выполнении ими работ по обслуживанию и ремонту расположенных на земельных участках и (или) под поверхностью земельных участков объектов системы газоснабжения, нефтепроводов и нефтепродуктопроводов, аммиакопроводов, по предупреждению чрезвычайных ситуаций, по ликвидации последствий возникших на них аварий, катастроф.»;

6) статью 33 признать утратившей силу;

7) статью 38 изложить в следующей редакции:

«Статья 38. **Возмещение убытков при ухудшении качества земель, ограничении прав собственников земельных участков, землепользователей, землевладельцев и арендаторов земельных участков, правообладателей расположенных на земельных участках объектов недвижимости**

Возмещение убытков при ухудшении качества земель, ограничении прав собственников земельных участков, землепользователей, землевладельцев и

арендаторов земельных участков, правообладателей расположенных на земельных участках объектов недвижимости осуществляется в соответствии с Земельным кодексом Российской Федерации.».

**Статья 2**

Подпункт «б» пункта 6 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 28 апреля 2007 года № 18-ЗРТ «О внесении изменений в Земельный кодекс Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2007, № 4; 2014, № 5; 2015, № 7 (I часть) признать утратившим силу.

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
22 декабря 2018 года
№ 111-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы**
**Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның $6^1$ пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$6^1$) ачык сервитутлар билгеләү турында үз компетенциясе чикләрендә карарлар кабул итү; Россия Федерациясе Җир кодексының $V^7$ бүлегендә каралган очраклардан тыш, Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибен раслау; Россия Федерациясе Җир кодексында яисә федераль законда каралган очраклардан тыш, ачык сервитут өчен тиешле түләү билгеләү һәм аны түләү тәртибен раслау; Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә карата сервитут билгеләү турында килешү буенча түләүне билгеләү тәртибен раслау;»;

2) 11 статьяда:
а) 3 пунктта:
беренче абзацта «саклау, санитар-яклау зоналары һәм» сүзләрен, «бүтән» сүзен төшереп калдырырга;
икенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;
б) 4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 12 статьяда:

а) 6 пунктта өченче һәм дүртенче җөмләләрне төшереп калдырырга;

б) 7 пунктның 2 пунктчасында җөмлә башына «федераль законда билгеләнгән очракларда махсус сакланылучы табигать территорияләре чикләрендә (махсус сакланылучы табигать территориясен зоналаштыру очрагында – әлеге территориягә урнашкан, федераль закон нигезендә билгеләнгән режимы тиешле объектлар урнаштыруны тыя торган функциональ зоналар чикләрендә)» сүзләрен өстәргә;

4) 13 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13 статья. **Урман фонды җирләре**

1. Урман фонды җирләренә составлары урманга кагылышлы законнар белән билгеләнә торган урман җирләре һәм урман булмаган җирләр керә.

2. Урман фонды җирләреннән файдалану һәм аларны саклау тәртибе Россия Федерациясе Җир кодексы һәм урманга кагылышлы законнар белән билгеләнә.»;

5) $28^1$ статьяда:

а) исемендә «Торба үткәргечләрнең» сүзләреннән соң «(газүткәргечләрнең, нефть үткәргечләрнең һәм нефть продуктлары үткәргечләрнең, аммиак үткәргечләрнең)» сүзләрен өстәргә;

б) 1 пунктта «Торба үткәргечләрнең» сүзләреннән соң «(газүткәргечләрнең, нефть үткәргечләрнең һәм нефть продуктлары үткәргечләрнең, аммиак үткәргечләрнең)» сүзләрен өстәргә;

в) 2 пунктта «торба үткәргечләрне» сүзеннән соң «(газүткәргечләрне, нефть үткәргечләрне һәм нефть продуктлары үткәргечләрне, аммиак үткәргечләрне)» сүзләрен өстәргә;

г) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

д) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Җир кишәрлекләре милекчеләре һәм җир кишәрлекләре милекчеләре булмаган затлар оешмага – газ белән тәэмин итү системасы объекты, нефть үткәргеч яисә нефть продуктлары үткәргеч милекчесенә йә ул вәкаләт биргән оешмага алар тарафыннан җир кишәрлекләрендә һәм (яисә) җир кишәрлекләре астында урнашкан газ белән тәэмин итү системасы объектларына, нефть үткәргечләргә һәм нефть продуктлары үткәргечләргә, аммиак үткәргечләргә хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, аларда булган һәлакәтләрдән, катастрофалардан килгән зыяннарны бетерү эшләрен башкаруны оештыруга комачауламаска тиеш.»;

6) 33 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 38 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«38 статья. **Җирләрнең сыйфатын начарайтканда, җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең һәм җир**

**кишәрлекләрен арендалаучыларның, җир кишәрлекләрендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары хокукына ия булучыларның хокукларын чикләгәндә зыянны каплау**

Җирләрнең сыйфатын начарайтканда, җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларның, җир кишәрлекләрендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары хокукына ия булучыларның хокукларын чикләгәндә зыянны каплау Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 28 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 6 пунктының «б» пунктчасын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 4; 2014, № 5 ; 2015, № 7 (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 22 декабрь
№ 111-ТРЗ